**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 19 октябрь | № 781

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1143 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Кадрлар әзерләү һәм тармакны үстерү комплекслы үзәге» дәүләт казна учреждениесен оештыру турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1143 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 12 февраль, 80 нче карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «һәм Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү, шулай ук медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта дәвалану урынына түләүсез бару һәм аннан кире кайту рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тапшыру турында Россия Федерациясенең Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте арасындагы килешүне тормышка ашыру максатларында,» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик санын 71,5 берәмлек итеп билгеләргә.»;

6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков